# КАРАР

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Яңа Иглай авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«11» ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 11 ноябрендә узган: «Яңа Иглай авыл җирлегендә яшәүче 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, ялгыз яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәкләрдән кала 2023 елда балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатында суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау һәм төзү-монтаж эшләре өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Яңа Иглай авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- Яңа Иглай авылында урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Яңа Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Яңа Иглай авылында халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 328 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 192 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 184 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 8 катнашучысы тавыш бирде.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Яңа Иглай авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Яңа Иглай авыл җирлегендә яшәүче 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, ялгыз яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәкләрдән кала 2023 елда балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатында суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау һәм төзү-монтаж эшләре өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Яңа Иглай авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;
- Яңа Иглай авылында урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;
- Яңа Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;
- Яңа Иглай авылында халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Р. Рахмәтуллин

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Рәхмәтуллин